**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 20 гыйнвар № 17

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларның фәнни-техник, инновацион, шул исәптән нанотехнологик тармакларны, фәнни-техник мәгълүмат системасын, интеллектуаль милек базарын үстерүгә юнәлдерелгән чараларны оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 26 октябрь, 804 нче карары белән расланган Юридик затларның фәнни-техник, инновацион, шул исәптән нанотехнологик тармакларны, фәнни-техник мәгълүмат системасын, интеллектуаль милек базарын үстерүгә юнәлдерелгән чараларны оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларның фәнни-техник, инновацион, шул исәптән нанотехнологик тармакларны, фәнни-техник мәгълүмат системасын, интеллектуаль милек базарын үстерүгә юнәлдерелгән чараларны оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 26 октябрь, 804 нче карары белән расланган Юридик затларның фәнни-техник, инновацион, шул исәптән нанотехнологик тармакларны, фәнни-техник мәгълүмат системасын, интеллектуаль милек базарын үстерүгә

юнәлдерелгән чараларны оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\17.docx

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 20 гыйнвар, 17 нче карары белән расланды

Юридик затларның фәнни-техник, инновацион, шул исәптән нанотехнологик тармакларны, фәнни-техник мәгълүмат системасын, интеллектуаль милек базарын үстерүгә юнәлдерелгән чараларны оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм юридик затларның фәнни-техник, инновацион, шул исәптән нанотехнологик тармакларны, фәнни-техник мәгълүмат системасын, интеллектуаль милек базарын үстерүгә юнәлдерелгән чараларны оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (алга таба – субсидия) бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына (алга таба – Министрлык) расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары кысаларында бирелә.

3. Субсидияләр юридик затларның (дәүләт (муниципаль) учреждениеләрдән тыш) субсидия бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзергә планлаштырылган айга кадәрге айның 1 числосына түбәндәге шартларга җавап биргәннәренә бирелә:

чит ил юридик затлары, шулай ук теркәлү урыны салым салуның ташламалы режимын бирә торган һәм (яки) мондый юридик затларга мөнәсәбәттә финанс операцияләрен үткәргәндә мәгълүматны ачу һәм бирүне күздә тотмый торган (офшор зоналар) дәүләтләр һәм территорияләрнең Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган исемлегенә кертелгән дәүләтләр һәм территорияләр булган чит ил юридик затлары катнашу өлеше устав (тупланма) капиталларында тулаем алганда 50 проценттан артып киткән россия юридик затлары булмаса;

үзгәртеп төзү, бетерү яки банкротлык процессында булмаса һәм хуҗалык эшчәнлеге алып баруда чикләүләре булмаса;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына һәм дәүләт бюджеттан тыш фондларына Россия Федерациясе законнары нигезендә түләү вакыты җиткән салымнар, җыемнар һәм бүтән мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмаса;

Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына субсидияләр, шул исәптән бүтән хокукый актлар нигезендә бирелгән бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча вакыты чыккан бурычы һәм Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына вакыты чыккан бүтән бурычы булмаса;

әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга бүтән норматив хокукый актлар, муниципаль хокукый актлар нигезендә Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан акча алмаса;

субсидия бирүгә заявка (алга таба – заявка) биргән көндә уртача айлык хезмәт хакын Татарстан Республикасы буенча эшкә яраклы халык өчен билгеләнгән яшәү минимумы зурлыгыннан түбән булмаган дәрәҗәдә сакласа;

элек бирелгән бюджет акчасын максатчан файдаланмауны һәм (яки) нәтиҗәсез файдалануны рөхсәт итмәсә.

4. Субсидия алу өчен юридик затлар Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

Министрлык раслаган форма буенча заявканы;

финанс-икътисадый нигезләмә теркәп, әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән чараларны тормышка ашыруга юнәлдерелгән чыгымнар сметасын;

юридик затны гамәлгә кую документлары, шулай ук аларга кергән барлык үзгәрешләр турында документлар күчермәләрен;

субсидия күчерелә торган счетлар турында мәгълүматны.

Документлар күчермәләре, аларның төп нөсхәләрен күрсәткәч, Министрлыкның документларны кабул итүче хезмәткәре тарафыннан раслана.

5. Юридик затлар үзләре теләге белән Министрлыкка түбәндәге документларны тапшырырга хокуклы:

юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсен;

салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсен;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтәне;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына мәҗбүри түләүләр буенча кредит бурычы булмауны раслаган документ.

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына һәм дәүләт бюджеттан тыш фондларына Россия Федерациясе законнары нигезендә түләү вакыты җиткән салымнар, җыемнар һәм бүтән мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары юклыкны раслый торган документны.

6. Юридик зат тарафыннан әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән документлар тапшырылмаган очракта, Министрлык күрсәтелгән документларны ведомствоара мәгълүмати багланышлар тәртибендә соратып ала.

7. Министрлык:

заявкаларны, алар кергән көндә журналга терки, ул сан сугылган, шнурланган һәм мөһер белән таныкланган булырга тиеш;

заявка теркәлгән көннән соң бер эш көне эчендә тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 4 пунктына туры килүенә карап тикшерә;

әлеге пунктның өченче абзацында билгеләнгән вакыт үткән көннән соң бер эш көне эчендә субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту хакында карар кабул итә һәм бу хакта гариза бирүчегә хәбәр итә.

8. Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

тапшырылган мәгълүматларның дөрес булмавы яки таләп ителә торган документларны бирмәү (тулы күләмдә бирмәү);

гариза бирүченең әлеге Тәртипнең 3 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве.

9. Юридик затка бирелә торган субсидия зурлыгы түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С = З1 + З2 + З3 +...+Зn,$$

монда:

С – юридик затка бирелә торган субсидия зурлыгы;

З1, З2, З3…Зn – субсидия исәбеннән каплана торган чыгымнар, алар составына түбәндәгеләр белән бәйле нигезле һәм документлар белән расланган чыгымнар керә:

чаралар үткәрү өчен биналар, ачык мәйданнарны арендалау;

чаралар үткәрү өчен тавыш һәм яктылык җайланмаларын, мультимедия җайланмаларын һәм бүтән инвентарьны арендалау;

чаралар үткәрү өчен биналарны, ачык мәйданнарны декорация-техник бизәү өчен түләү, җайланмаларны монтажлауны (демонтажлауны) кертеп;

транспорт хезмәтләре өчен түләү;

чаралар үткәрү кысаларында бирелә торган призлар, бүләкләр һәм сувенирлар алуга;

чаралар үткәрү белән бәйле чакыру билетларын, реклама һәм мәгълүмат материалларын тиражлаганда полиграфия һәм нәшрият хезмәтләре өчен түләү;

оештыру чыгымнары һәм чаралар үткәрүгә хезмәт күрсәтү;

чаралар оештыру һәм үткәрү өчен граждан-хокук шартнамәләре нигезендә, шул исәптән автор шартнамәләре нигезендә җәлеп ителгән белгечләр хезмәте өчен түләү.

10. Субсидия бирү Министрлык һәм юридик зат арасында төзелгән килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

Килешү субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән ике көн эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән үрнәк форма нигезендә төзелә.

Килешүдә субсидиянең күләме, аның максатчан билгеләнеше, чараларны оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгым төрләре, субсидияне файдалану турында хисап тапшыру тәртибе, рәвеше һәм вакытлары, субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмаган өлешен субсидия алучы тарафыннан агымдагы финанс елында кире кайтару очраклары һәм тәртибе, субсидия алучының Министрлык, дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан субсидия алучының субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүләргә ризалыгы (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләр, устав (тупланма) капиталларында гавәми-хокукый оешмалар катнашында хуҗалык иптәшлекләре һәм җәмгыятьләре, шулай ук устав (тупланма) капиталларында мондый иптәшлекләр һәм җәмгыятьләр катнашында коммерциячел оешмалардан тыш), субсидия алучы тарафыннан әлеге Тәртипнең һәм төзелә торган килешүнең шартларын үтәү турында нигезләмәләр урын ала.

11. Министрлык тарафыннан субсидия бирү турында карар кабул ителгәннән соң эш көннәрендә исәпләнгән ун көн эчендә Министрлык субсидияне субсидия алучының россия кредит оешмасында ачылган исәп-хисап счетына күчерә.

12. Субсидия алучы килешүдә каралган тәртиптә, вакытларда һәм рәвештә Министрлыкка субсидияне файдалану турында хисап тапшыра.

13. Субсидия түбәндәге очракларда Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән 30 көн эчендә субсидия алучы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш:

субсидия алу өчен дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырганда;
субсидия бирү шартлары бозылганда;
билгеләнгән вакытта субсидияне файдалану турында хисап тапшырылмаганда;
субсидия акчасын максатчан файдаланмаганда.

14. Килешүдә каралган очракларда субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмаган өлеше хисап елыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр субсидия алучы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

15. Субсидия алучы әлеге Тәртипнең 12 һәм 13 пунктларында күрсәтелгән субсидияне кире кайтару вакытларын бозган очракта Министрлык субсидияне кире кайтару вакыты узган көннән соң эш көннәрендә исәпләнелгән җиде көн эчендә күрсәтелгән акчаны законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча чаралар күрә.

Күрсәтелгән акчаны Татарстан Республикасы бюджеты кеременә ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тартылган очракта алар Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри тәртиптә кайтартылырга тиеш.

16. Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары субсидия алучылар тарафыннан субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерүләрне законнарда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыра.

17. Субсидияләрне максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тикшерүдә тотуны Министрлык законнар нигезендә гамәлгә ашыра.